ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2025 г.Казань № 333-37/тэ-2025

Түбән Кама шәһәренең социаль әһәмиятле кулланучыларның аерым категорияләре (төркемнәре) өчен җылылык энергиясен куллану булмаганда резерв җылылык егәрлеген саклап калу буенча «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр өчен түләү билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 21.11.2025 ел, № 26-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә Түбән Кама шәһәренең социаль әһәмиятле кулланучыларның аерым категорияләре (төркемнәре) өчен җылылык энергиясен куллану булмаганда резерв җылылык егәрлеген саклап калу буенча «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр өчен түләү билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән түләү карар үз көченә кергән көннән 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
21.11.2025 № 333-37/тэ-2025
карарына кушымта

Түбән Кама шәһәренең социаль әһәмиятле кулланучыларның аерым категорияләре (төркемнәре) өчен җылылык энергиясен куллану булмаганда резерв җылылык егәрлеген саклап калу буенча «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр өчен түләү

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Ел | Резерв җылылык егәрлеген саклау хезмәтләре өчен түләү, айга сум/Гкал/сәг. |
|---|---|---|---|
| | Түбән Кама шәһәре | | |
| 1 | «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте | ________________ № ____ карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2025 кадәр | 93 035,21 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге